УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Федосеевская, 36, г. Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ
Федосеев ур., 36, Казан шәһәре, 420111

ПРИКАЗ　　　　БОЕРЫК
07.12.2018　　　　№ 01-05/329-пр

Казан ш.

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 2018 елның 16 маендагы 01-05/122-пр номерлы боерыгы белән расланган Белем бирү процессының җиһазлау һәм җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында таныклык бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары нигезендә

БОЕРЫК БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 2018 елның 16 маендагы 01-05/122-пр номерлы боерыгы белән расланган Белем бирү процессының җиһазлау һәм җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында таныклык бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктның 1.4.2 пунктчасында:

беренче абзацта «дәүләт хезмәте турында» сүзләреннән соң «, шулай ук Идарәнең урнашкан урыны һәм эш графигы турында» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «дәүләт хезмәте турында» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә» сүзләрен өстәргә;

1.6 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль район (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).»;

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Югарыда саналган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагында булган документларны, шулай ук кабул итүдән яисә дәүләт хезмәтен яки муниципаль хезмәтне күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән, дәүләт хезмәтен яки муниципаль хезмәтне күрсәтү өчен кирәкле документларны таләп итү тыела, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында «а»-«г» пунктчаларында санап үтелгән очраклардан тыш;

3.5 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«3.5. Тапшырылган документларны тикшергәннән соң баш дәүләт инженер-инспекторы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасы аша дәүләт пошлинасының түләнүе турында белешмәләр ала.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт пошлинасын түләү турында белешмәләр алу.»;

5 бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Идарәнең, шулай ук аның вазыйфаи затларының һәм дәүләт граждан хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.2 пунктында:

3 пунктчада «каралмаган документларны тапшыруны» сүзләрен «тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматны тапшыруны яисә гамәлләрне башкаруны» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 10 пунктча өстәргә:

«10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп иткәндә».»;

5.7 пунктка түбәндәге эчтәлекле $5.7^1$, $5.7^2$ пунктчалар өстәргә:

«$5.7^1$. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта җавапта

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Идарәдә гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.7². Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.».

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык Р.Р. Зыятдинов